**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 с., Атабаево
ул. Молодежная , дом 1
тел:/факс: 8(84378) 4-87-41
e-mail:Atab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АТАБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422635, Атабай авылы,
Яшьләр урамы, 1 йорт
тел:/факс: 8(84378) 4-87-41
e-mail:Atab.La@tatar.ru

---

**2025 елның 25 декабре** **22 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш)**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш), Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 24 апрелендәге 132 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның хезмәт хакы түбәндәге зурлыкта билгеләнә:

| **Вазифа** | **Халык саны белән муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты** |
|---|---|
| | **3,5 мең кешегә кадәр** |
| **Баш бухгалтер** | **31 000 рублей** |

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының штат расписаниесенә баш бухгалтер вазифасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 мең кешедән артык.».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Атабай**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.И.Билялов**